ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ
КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ　　　　　БОЕРЫК

__21.10.2022_______　　　Казан шәһәре　　　№ ___118____

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 13 августындагы 64 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 13 августындагы 64 номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча һәм Хокук идарәсе» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар һәм Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

боерык белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибендә:

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгать, аны Инспекциядә теркәгән көннән соң киләсе көннән соңга калмыйча, Инспекция җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә, Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенә, шулай ук Инспекциядә коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган затка (алга таба – җаваплы зат) карау өчен җибәрелә.»;

4 пунктның беренче абзацында «дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

беренче абзацта:

«җитәкчесе» сүзеннән алда «Инспекция» сүзе белән тулыландырырга;

«(аның вазыйфаларын башкаручы зат)» сүзләреннән соң «әлеге бәяләмәне алганнан соң биш эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «тиешле мәгълүмат» сүзләреннән соң «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта» сүзләрен өстәргә»;

6 пунктның икенче абзацында «дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча, шулай ук Хокук идарәсе» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар, шулай ук Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсе» сүзләре белән алмаштырырга;

7 пунктта «дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча, шулай ук Хокук идарәсе» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар, шулай ук Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсе» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенең хокук бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ һәм мәгълүмат технологияләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче В.А. Кудряшов